Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының

Байлангар авыл җирлеге Башлыгы карары

10 ноябрь, 2023 ел № 5

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 адресында урнашкан Байлангар авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2023 елның 23 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 адресында урнашкан Байлангар авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»
500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү

- янгын гидранты һәм комплектлау өчен детальләр сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)

- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)

- Совет урамы тыкрыгын төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

- ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру, ял итү зоналарын төзекләндерү; Сабантуй бәйрәме уздырыла торган урын территориясен төзү һәм төзекләндерү; (сәхнәне, тамашачылар өчен эскәмияләрне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү; материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү (инструментлар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Сууткәргеч челтәрләрен һәм су суырту манараларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (Байлангар авылында су суырту манараларын буяу, артезиан скважинасы өчен насослар сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Урам яктыртуны карап тоту; (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Байлангар авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Байлангар авылы урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю (килешү буенча түләү)

- Байлангар авылының Гагарин урамына асфальт салу

- Байлангар авылында автомобиль күпере төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

- Байлангар авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» - ?　　　　　　　　　　«КАРШЫ» - ?

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Байлангар авылы Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы:　　　　　　　　И.Ф. Кәримуллин

ОГРН 1021607752814 ИНН 1623001621